**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5711**
**03.07.2023**

Башкарма комитет карарлары үз
көчен югалтуны тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 18 сентябрендәге 2113-р номерлы Боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган типовой дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләренең гомуми файдаланудагы мөлкәтенә караган җир участогын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 12 августындагы 4781 номерлы;

2) «Муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4349 номерлы;

3) «Муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 22 июнендәге 3190 номерлы;

4) «Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4349 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 12 ноябрендәге 6625 номерлы;

5) «Башкарма комитетның 2015 елның 31 июлендәге 4349 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 мартындагы 1142 номерлы карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов